Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

23 апрель, 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башлыгының 2020 елныц 24 мартындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 66 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» (25.05.2018 ел, № 93, 20.10.2019 ел, № 131 үзгәрешләр белән) карары, Россия Федерациясе Президентының яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, республикада махсус санитар-эпидемиология режимы кертелүгә бәйле рәвештә һәм гражданнар сәламәтлеге өчен хәвеф-хәтәрләр килеп чыкмасын өчен, Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турындагы 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Надеждино авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2020 елның 24 мартындагы 1 номерлы карарына **түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:**

1.1. 2 пунктындагы 2.2. һәм 2.3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. гавами тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2020 елның 7 мае, 14.00 сәгатьтә Надеждино авылы, Мәктәп урамы, 3 йорт, Надеждино авыл мәдәният йортының тамаша залы;

2.3. Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне, авторның фамилиясен, исемен, әтисенең

туган елын, яшәү урынын күрсәтеп, nad.pes@tatar.ru  электрон адресына җибәр ала;»

1.2. 3 пунктның 3.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. 2020 елның 13 маена кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Питрәч муниципаль районының Интернет челтәрендә рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында таратырга, бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И. З. Галәветдинов